ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**23.01.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 120**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының карарлары үз көчләрен югалтуын тану хакында

2023 елның 23 декабрендәге «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарлары үз көчләрен югалтуын танырга:

2021 елның 13 августындагы «Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 1926 номерлы;

2021 елның 13 августындагы «Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 1919 номерлы;

2021 елның 13 августындагы «Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 1909 номерлы;

2021 елның 13 августындагы «Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 1921 номерлы;

2021 елның 13 августындагы «Җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 1924 номерлы;

2021 елның 26 июлендәге «Территорияне планлаштыру документациясен әзерләү һәм раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 1738 номерлы;

2021 елның 15 октябрендәге « Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган белешмәләрне, документларны, материалларны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламенты» 2547 номерлы.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин